КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 30 май г.Казань № 659

2022 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә 2023 елда бер тапкыр бирелә торган түләү турында

Мәгариф лидерларына ярдәм күрсәтү, алдынгы идарә итү һәм педагогик тәҗрибәне тарату, белем бирү сыйфатын яхшырту һәм Татарстан Республикасы педагогик хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә 2023 елда 30,0 мең сум күләмендә бер тапкыр бирелә торган түләү (алга таба шул ук эзлеклелектә – бер тапкыр бирелә торган түләү, Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләре) билгеләргә.

2. Бер тапкыр бирелә торган түләү Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирә торган мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган мәгариф оешмаларының педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен премияләр түләнә торган укытучылары исемлеген раслау турында» 2022 елның 16 августындагы 739 номерлы боерыгы белән расланган Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирә торган мәгариф программалары гамәлгә ашырыла торган мәгариф оешмаларының педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен премияләр түләнә торган укытучылары исемлегенә укытучылары кертелгән Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә бирелә дип билгеләргә.

3. Бу карарны тормышка ашыруга бәйле чыгымнарны финанслау «2023 елга, 2024 һәм 2025 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 2022 елның 23 ноябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы өчен әлеге максатларга каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына 60 көн эчендә 2022 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә бер тапкыр бирелә торган түләү бирү тәртибен эшләргә һәм расларга.

5. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2021 елда педагогик эшчәнлектәге казанышлар өчен Татарстан Республикасының иң яхшы укытучыларына премияләр бирү конкурсында җиңүче укытучылар эшли торган гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә 2022 елда бер тапкыр бирелә торган түләү турында» 2022 ел, 18 июль, 689 нчы карары үз көчен югалткан дип танырга.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин